Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының
Шәле авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

8 февраль, 2021 ел № 4

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 11 апрелендәге 10 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп), муниципаль районның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.2. 1.5. пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«җирле үзидарә органнары бирә торган белешмәгә (өземтә) дигәндә хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, гаилә составы турындагы белешмә, көнкүреш характеристикасы керә.»;

1.3. 2.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Муниципаль хезмәт күрсәтүләрне алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне таныклый торган документ;

2) мөрәҗәгать итүче вәкил вәкаләтләрен таныклаучы документ, муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш);

3) гариза:

- кәгазь чыганактагы документ рәвешендә (1 нче кушымта);

- республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, «Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон рәвештә (интерактив формага тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла);

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк булган очракта һәм әгәр федераль закон нигезендә

мондый шәхси белешмәләрне эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән башкарылырга мөмкин булса, муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә күрсәтелгән затның яисә аның күрсәтелгән затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртүгә законлы вәкиленең ризалыгын алуны раслый торган документлар тапшыра. Рөхсәт алуны раслаучы документлар шул исәптән электрон документ формасында да тапшырылырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм кушып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

- шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат);
- почта аша.

Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан Республика порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшырылырга мөмкин (җибәрелергә).»;

1.4. 1 нче кушымтаны яңа редакциядә итеп бәян итәргә;

1.5. 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Питрәч муниципаль районының
Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов

Кушымта №1

____________________________________________
(муниципаль берәмлекнең
____________________________________________
җирле үзидарә органы исеме)
____________________________________________
____________________________________________
________________ (алга таба - мөрәҗәгать итүче).
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны буенча теркәлү урыны, телефон)

# ГАРИЗА
## белешмә (өземтә) бирү турында

Сездән, ________________________ белешмә (өземтә) бирүегезне сорыйм.
(белешмәнең төрен күрсәтү)
Түбәндәге адрес буенча: ______________________________________________
____________________________________________________________________

Гаризага түбәндәге документларны терким:

1. __________________________________________________________________
2. __________________________________________________________________
3. __________________________________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә түбәндәге ысул белән хәбәр итүегезне сорыйм _____________________________________

________________/_________________/___________________________
(дата) (имза) (Ф.И. атасының исеме.)